**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 16.09.2022** **№ 925**

# Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Айбаш авыл җирлеге генераль планы проектын килештерү буенча Килештерү комиссиясен төзү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 25 статьясы нигезендә, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Айбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проекты буенча каршылыкларны җайга салу буенча Килештерү комиссиясен төзергә.
2. Кушымтада бирелгәннәрне расларга:
Килештерү комиссиясе эшчәнлеге тәртибен. (1 нче кушымта)
Килештерү комиссиясе составын. (2 нче кушымта).
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге башлыгы А. М. Хөснетдиновка йөкләргә.

Җитәкченең беренче урынбасары Д.Ф. Шәйдуллин

1 нче кушымта
РАСЛАНДЫ
Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 16.09.2022 925нче номерлы карары белән

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы «Айбаш авыл җирлеге» мунииипаль берәмлегенең Генераль планы проекты буенча каршылыкларны җайга салу буенча килештерү комиссиясе эшчәнлеге тәртибе**

1. Килештерү комиссиясе үзенең эшчәнлегендә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 25 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе региональ үсеш министрлыгының "Муниципаль берәмлекләрнең территориаль планлаштыру документлары проектларын килештерү тәртибен, территориаль планлаштыру документлары проектларын килештергәндә, Килештерү комиссиясенең составын һәм эш тәртибен раслау турында" 2016 елның 21 июлендәге 460 номерлы боерыгына, Биектау муниципаль районы Уставына таяна.

2. Килештерү комиссиясе үз эшчәнлеген дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка кызыксынган затлар белән хезмәттәшлек итеп гамәлгә ашыра.

3. Килештерү комиссиясенең максималь эш вакыты аны төзегән көннән өч айдан артык була алмый.

4. Килештерү комиссиясен төзү датасы дип Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының Килештерү комиссиясе эшчәнлеге тәртибен һәм составын раслау турында карарын Биектау муниципаль районының Рәсми сайтында бастырып чыгару датасын санарга.

5. Килештерү комиссиясе утырышын Рәис оештыра һәм алып бара, ә ул булмаганда - Килештерү комиссиясе рәисе урынбасары.

6. Килештерү комиссиясе утырышларында комиссия әгъзалары катнаша, ә кирәк булганда, Килештерү комиссиясе утырышларында гамәлдәге законнар нигезендә башка органнар вәкилләре дә катнаша ала.

7. Килештерү комиссиясе утырышы, исемлек составының 50% ким булмаган өлеше катнашса, хокуклы дип санала.

8. Килештерү комиссиясе утырышы беркетмәсе рәис һәм секретарь тарафыннан имзалана.

9. Килештерү комиссиясе тарафыннан кабул ителгән карарларга каршы тавыш биргән Килештерү комиссиясе әгъзалары беркетмәгә кушылачак һәм аның аерылгысыз өлеше булып торган махсус фикер итеп рәсмиләштерә алалар.

10. Килештерү комиссиясе карары утырышта катнашучы әгъзаларның гади күпчелеге тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, Килештерү комиссиясе рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

11. Килештерү комиссиясенең эш нәтиҗәләре Килештерү комиссиясе утырышы беркетмәсендә чагыла.

12. Килештерү комиссиясе үз эше нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

12.1. Территориаль планлаштыру документы проектын әлеге проект белән килешмәү өчен нигез булып торган барлык кисәтүләрне исәпкә ала торган аңа үзгәрешләр кертү белән килештерергә.

12.2. Территориаль планлаштыру документы проектын, килештерүдән баш тарту турында Карар кабул итүгә нигез булган сәбәпләрне күрсәтеп, килештерүдән баш тартырга.

13. Үз эшенең нәтиҗәләре буенча Килештерү комиссиясе Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә түбәндәгеләрне җибәрә:

13.1 Тәртипнең 12 пунктының 12.1 пунктчасында күрсәтелгән карарны кабул иткәндә, килештерелмәгән мәсьәләләр буенча текст формасында һәм карталар рәвешендә материаллары белән, аңа кертелгән үзгәрешләр белән территориаль планлаштыру документы проектын Килештерү комиссиясе утырышы беркетмәсе белән бергә.

13.2 Тәртипнең 12 пунктындагы 12.2 пунктчасында күрсәтелгән карарны кабул иткәндә, территориаль планлаштыру документының килештерелмәгән проекты, территориаль планлаштыру документы проекты белән килешмәү турында бәяләмә, Килештерү комиссиясе утырышы беркетмәсе, шулай ук килештерелмәгән мәсьәләләр буенча текст формасында һәм карта рәвешендә материаллар.

12 пунктның 12.2 пунктчасында күрсәтелгән документлар һәм материаллар үз эченә ала:

Килештерелмәгән мәсьәләләр буенча материалларны территориаль планлаштыру документы проектыннан төшереп калдыру турында тәкъдимнәр (шул исәптән килештерелмәгән мәсьәләләрне килештергәнче теркәү максатларында тиешле картада күрсәтү юлы белән);

Тәртипнең 12 пунктының 12.1 пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләләрне, мондый территориаль планлаштыру документына тиешле үзгәрешләрне кертү тәкъдимнәрен әзерләү юлы белән территориаль планлаштыру документын раслаганнан соң, килештерү планы.

14. Килештерү комиссиясе тарафыннан тапшырылган беркетмәләр һәм материаллар нигезендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының территориаль планлаштыру схемасына үзгәрешләр кертү килештерелгән яки аерым өлешендә килештерелмәгән проектын раслауга яки раслаудан баш тартып, аны эшләп бетерергә җибәрә.

15. Килештерү комиссиясе адресына язмача бирелә торган гаризаларга һәм сорауларга җаваплар Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән срокта бирелә.

16. Килештерү комиссиясенең карарларына Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

2 нче кушымта
РАСЛАНДЫ
Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 16.09.2022 №925нче номерлы карары белән

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы «Айбаш авыл җирлеге» мунииипаль берәмлегенең Генераль планы проекты буенча каршылыкларны җайга салу буенча килештерү комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Хәкимуллин Р.Ф. | Комиссия рәисе, Башкарма комитет җитәкчесенең төзелеш, архитектура һәм ТКХ буенча урынбасары |
| Әхмәтҗанов А.Х. | Комиссия секретаре, төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлегенең баш белгече |
| Комиссия әгъзалары | |
| Таҗиев И.И. | Район Советының юридик бүлеге башлыгы |
| Хөснетдинов А.М. | Төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге башлыгы |
| Вәкил | Төзелеш, архитектура һәм ТКХ министрлыгы (килештерү буенча) |